Кама Тамагы муниципаль районы татар теле һәм әдәбияты укытучыларының "Укытучының профессиональ стандарты" темасы буенча август киңәшмәсе утырышына

# Доклад

## Тема: "Татар теле һәм татар әдәбияты дәресләрендә укучыларның фәнни-тикшеренү эшчәнлеген оештыру"

Чыгышны әзерләде:
В.П. Муравьев исемендәге Затон урта гомуми белем бирү мәктәбенең
югары категорияле татар теле
һәм әдәбияты укытучысы
Лизунина Эльвира Хәмзә кызы.

2016 ел

Укучыларны фән дөньясына алып керү, кызыксындыру, аларны тикшеренү эшләренә җәлеп итү проблемасы уйландыра. Рус мәктәпләрендә эшләүче татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен бу аеруча мөһим. Ник дигәндә, мондый мәктәпләрдә белем алучы балалар арасында татар теле һәм әдәбияты белән кызыксынучыларның саны артык күп түгел. Ә укучыларны эзләнү-тикшеренү белән шөгыльләндерә алу бик зур мөмкинлекләр ача, укучыларның сөйләм телен, иҗади сәләтен үстерергә ярдәм итә.

Укучы күзлегеннән эзләнү-тикшеренүне оештырып башкару – ул максималь рәвештә үзеңнең иҗади потенциалыңны күрсәтү. Бу төр эшчәнлек коллективта үзеңнең индивидуальлегеңне күрсәтә алырга, билгеле белемнәрен һәм көчең ярдәмендә нинди дә булса уңышка ирешергә ярдәм итә. Бу төр эшчәнлекнең иң әһәмиятлесе – ул кызыклы бер проблеманы чишергә алынып һәм укучылар тарафыннан бурычлар рәвешендә формалаштырылып, чишелеш ысулларын куллану аша нинди дә булса бер нәтиҗәгә килү. Эзләнү-тикшеренү эшчәнлеге – укучыларда проектлаштыру һәм тикшерүнең үзенчәлекле күнекмәләрен һәм осталыкларын барлыкка китерә һәм үстерә торган интегратив дидактик үстерү, белем һәм тәрбия бирү чарасы.

“Кошлар тумый канатсыз. Кеше тумый талантсыз”, - диелә татар халык мәкалендә. Чыннан да, һәр кешедә нинди дә булса бер шөгыльгә сәләт булмый калмый. Мәктәптә эшләү дәверендә мин шуңа инандым: һәр сыйныфта да сәләтле, кызыксынучан балалар була, бары тик аларны вакытында барлап, сәләтләрен тиешле юнәлештә үстерүне оештыра белергә генә кирәк. Белгәнебезчә, бүгенге көндә рус мәктәпләренең рус төркемнәрендә татар балалары да белем ала. Алар татар сөйләмен аңлый, шуңа күрә дәресләр ул балалар өчен кызыксыз тоелырга мөмкин. Аларны ничек тә кызыксындырырга, алар белмәгән мәгълүматны бирергә кирәк. Шушы максатны күздә тотып, мин иң беренче дәресләрдә укучыларга татар теле, әдәбият дәреслекләре белән танышып чыгарга, үзләренә ошаган тема яки язучыны сайларга тәкъдим иттем. Кызыксындырган материалны ачыклагач, шул темалар, яки язучы иҗаты буенча укучылар төрле биремнәр эшләп карый. Мәсәлән, интернет челтәреннән кызыклы материал эзләп карау, билгеле бер темага мәкальләр яки табышмаклар барлау һ.б. Бу эш барышында сәләтле укучыларның мөмкинлекләре ачыла. Димәк, укучылар фәнни-гамәли конференциядә уңышлы чыгыш ясасын өчен аларда башта эзләнүчәнлек сәләтен үстерегә кирәк:

**1 этап**

- Диагностика (балаларның мөмкинлекләре ачыклана)
- Фәнгә сәләтле укучылар сайлана;

**2 этап**

- Эзләнү өчен шартлар тудырыла;

**3 этап**

- Индивидуаль консультацияләр;

Фәнни – тикшеренү эшчәнлеген оештыруда мин укучылыр белән эшләүнең төрле эш формаларын кулланам.

- **Индивидуаль** (доклад, чыгыш, реферат, фәнни хезмәтләрнең темаларын, әдәбият исемлеген сайларга ярдәм итәм, консультацияләр үткәрәм, киңәшләр бирәм, һ.б.ш.)
- **Төркемләп** (тикшерү проектлары күп мәгълүмат таләп иткәндә). (М.Мирза иҗаты буенча “Биш юлым – биш гөлем” дип аталган төркемләп эшләгән эш республикада 3 нче урынга лаек булды. 7 нче сыйныф укучысы Вилков Раил конференциядә чыгыш ясады)
- **Массакүләм** (укытучылар белән предмет атналыклары, олимпиадалар, семинар, конференцияләр һ.б.ш.). (“Мин татарча сөйләшәм” акциясе кысаларында материал туплау)

**Фәнни–тикшеренү эше алып бару алгоритмы;**

1. Тема сайлау;
2. Тема буенча мәгълүмат җыю, аны эшкәртү һәм системалаштыру;
3. Фәнни-тикшеренү эшенә таләпләр белән танышу;
4. Эшкә максат кую;
5. Максатка ирешү өчен бурычлар билгеләү;
6. Шул бурычлардан чыгып, фәнни хезмәтнең эчтәлеген төзү;
7. Максатка ирешү юлын модельләштерү. Модельләштерүнең максаты булып фәнни-теоретик фикерләрне формалаштыру, барлык тикшерелгән материалларны бер калыпка салу тора.

**Фәнни эшнең нәтиҗәсе :**

- Укучыларның конференцияләрдә катнашуы.
- Эшләрнең фәнни газета журнал һәм җыентыкларда бастырылуы.
- Махсус күнекмәләр барлыкка килү.

**Укучыларның фәнни хезмәтләренә куела торган таләпләр:**

- Фәнни хезмәт басма рәвештә 12-15 биттән артмаска, электрон варианта да булырга тиеш.
- Эчтәлек, кереш, төп өлеш, нәтиҗә, кулланылган әдәбият һәм фәнни хезмәтнең тезисы бырга тиеш,
- Рәсем, схема, фотосурәтләргә исем бирергә, битләрне нумерацияләргә тиеш.

**Фәнни эшең бәяләнү критерийлары**

- Теманың актуаль булуы;
- Максат һәм бурычларның дөрес куелуы;
- Кулланылган әдәбият һәм чыганакларның 3 тән ким булмавы;

- Эзләнү, яки эксперимент, нәтиҗә яки тәкъдим өлешләре булуы;
- Фәнни эшнең оформление буенча таләпләргә туры килүе;

Укучының эшен яклау моменты 5-7 минуттан артмаска тиеш.

“Укучысы укытучыдан күбрәк белергә тиеш” дип әйтсәләр дә, балага белем, кирәкле дөрес юнәлеш бирүче ул - аның остазы. Укучыбыз белемле булсын өчен, аның укытучысы киң карашлы, эрудицияле, замана сулышын тоеп яшәүче булырга тиеш.

Информацион-коммуникатив чаралар кулланып, мәктәп системасында фәнни эшчәнлекне оештыруның роле тагын да зуррак. Бу очракта мәктәп укучылар фәнни эш белән кызыксынып, теләп шөгыльләнәләр. Чөнки бүгенге көндә бу эш китап уку гына булып калмыйча, балалар теләгән интернет, телевидение, техника куллану аша башкарыла. Укучылар буш вакытларын кирәкле эшкә юнәлтәләр, белемле булалар, кешеләр белән аралашырга, үз фикерләрен җиткерергә, техника белән эш итәргә өйрәнәләр. Димәк мәктәп каршына куелган иң мөһим вазифалар үтәлә.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: фәнни эш белән шөгыльләнү укучыны күп нәрсәгә өйрәтә: уйлау мөмкинлекләре киң ачыла, логик фикерләү дәрәҗәсе үсә, төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эшләргә, төрле чыгышлар ясарга өйрәтә. Ә иң кыйммәте – аларда үз нәтиҗәләрен күргәннән соң иҗат дәрте кабынуы.